Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының кырык җиденче утырышы

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 117

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 10 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 10 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бер мандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 10 номерлы карарына кушымта итеп)кертеп төгәлләштерергә:

а) Ленино-Кокушкино № 1 бермандатлы сайлау округына Үзәк урамы буенча 13 нче йорт;

б) Ленино-Кокушкино № 3 бермандатлы сайлау округына Яшьләр урамы буенча 15 нче йорт;

в) Ленино-Кокушкино № 9 бермандатлы сайлау округына Үзәк урамы буенча 31 нче йорт;

г) Ленино-Кокушкино № 10 бермандатлы сайлау округына

- Кояшлы, Күл, Чокыр, Болын, Йолдызлы, Яр буе урамнары;
- Камалиев урамы буенча 106, 107, 108, 109, 110 йортлары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфутдинов